КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 февраль г.Казань № 42

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын һәм (яки) төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына чыгымнарны исәптән төшерү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 ел, 11 февраль, 91 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын һәм (яки) төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына чыгымнарны исәптән төшерү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 ел, 11 февраль, 91 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын һәм (яки) төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына чыгымнарны исәптән төшерү тәртибе турындагы нигезләмәнең 8 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиягә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәсе буенча уздырылган объектны тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирә.»;

әлеге карар белән расланган Финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын һәм (яки) төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына чыгымнарны исәптән төшерүне килештерү буенча комиссия составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 11 февраль, 91 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 1 февраль, 42 нче
карары редакциясендә)

Финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын һәм (яки) төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына чыгымнарны исәптән төшерүне килештерү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Долгов Марат Шамил улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары |
| Вилданов Данис Фәнил улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Әһлиуллин Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Гайнетдинов Ренат Вәгыйз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Данилов Эдуард Юрьевич | «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Миннәхмәтов Җәүдәт Мидхәт улы | «Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклаучы технологияләр һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна учреждениесе генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Ситдыйков Нияз Равил улы | «Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| | Татарстан Республикасы территориясендә тәгалләнмәгән төзелеш объекты урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы вәкиле (килешү буенча). |